**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 15 июлендәге 2986 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2010 елның 19 ноябрендәге 10376 номерлы**
**«Казан шәһәренең муниципаль милкен бушлай**
**файдалануга бирү турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре милке белән идарә итү һәм эш итү системасын камилләштерү, аннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 ноябрендәге 10376 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль милкен бушлай файдалануга бирү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 декабрендәге 10376 номерлы карарына кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 15 июлендәге
2986 номерлы карарына
кушымта
(Форма)

РАСЛЫЙМ
Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисенең беренче урынбасары
________________________________
Мөһер урыны
20__ елның «___» ____________

**Казан шәһәре муниципаль милкеннән**
**бушлай файдалану шартнамәсе**

Казан шәһәре 20__ елның «__» ___________ ______ номерлы

_______________________________________ (алга таба – «Ссуда бирүче») исеменнән _________________________ нигезендә эш итүче ____________________ бер яктан һәм ___________________________________________
__________________________________________(алга таба – «Ссуда алучы») исеменнән _____________________________нигезендә эш итүче ________________________икенче яктан түбәндәгеләр турында әлеге шартнамәне төзеделәр.

I. Шартнамә предметы

1.1. Ссуда бирүче түбәндәге муниципаль милекне________________ (алга таба – муниципаль милек) бушлай файдалануга тапшыра, ә Ссуда алучы кабул итә.

1.2. Муниципаль милекне бушлай файдалануга бирү милек хокукы Ссуда алучыга күчүгә китерми.

1.3. Бушлай файдалануга бирелгән муниципаль милекне тиешле хәлдә тоту өчен финанс чыгымнарын Ссуда алучы тулысынча үз өстенә ала. Ссуда алучы тарафыннан башкарылган муниципаль милекне аерылгысыз яхшыртулар Казан шәһәре муниципаль берәмлеге милке булып тора һәм аларны башкаруга тотылган чыгымнар кайтарылмый.

1.4. Муниципаль милекне бушлай файдалануга бирү тапшырыла торган объектның төгәл характеристикаларын һәм торышы турындагы белешмәләрне күрсәтеп тутырырлган кабул итү-тапшыру акты нигезендә башкарыла.

II. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Ссуда бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

2.1.1. әлеге шартнамә нигезендә муниципаль милекнең сакланышын һәм аннан

файдалануны контрольдә тотарга;

2.1.2. Ссуда алучының муниципаль милеккә карата хуҗалык эшчәнлеге алып баруын чагылдыра торган документлар белән танышырга.

2.1.3. урам-юл челтәре объектлары аларны реконструкцияләү максатыннан дәүләт катнашында оешмаларга бушлай файдалануга бирелгән очракта, яклар килешүе буенча күрсәтелгән муниципаль милекне карап тоту буенча финанс чыгымнары йөкләмәсен күтәрергә.[1]

2.2. Ссуда алучы бурычлы:

2.2.1. муниципаль милекне кабул итәргә һәм бухгалтерлык исәбе турында Россия Федерациясе законнары нигезендә аның буенча исәп-хисап алып барырга;

2.2.2. муниципаль милекне ______________________________________ максатыннан файдаланырга;

2.2.3. әлеге шартнамәнең 2.1.3 пунктында күрсәтелгән очраклардан кала, муниципаль милекне карап тоту, әлеге милекне, йорт янындагы территорияне һәм төзекләндерү объектларын тиешле хәлдә карап тоту буенча финанс чыгымнары йөкләмәсен (капиталь һәм агымдагы ремонт, теркәү, саклау, коммуналь түләүләр, махсус (техник, санитар һ.б.) тикшерү, янгынга каршы куркынычсызлыкны тәэмин итү, дәүләт янгын күзәтчелеге органнары күрсәтмәләрен үтәү, шулай ук Ссуда бирүчегә салынган милек салымын һәм җир кишәрлегеннән файдаланган өчен түләүне кире кайтару) алып барырга. Муниципаль милекне карап тоту һәм аннан файдалану, коммуналь хезмәтләр өчен түләүне Ссуда алучы бердәм түләү документы – Ссуда бирүче белән муниципаль милектәге торак булмаган урыннарны карап тотуга һәм алардан файдалануга шартнамә төзегән идарәче оешма тарафыннан бирелә торган счет-фактура нигезендә гамәлгә ашыра. Ссуда алучы шулай ук коммуналь һәм башка хезмәтләр күрсәтүче махсуслаштырылган оешмалар белән турыдан-туры килешүләр төзү хокукына ия;

2.2.3(а). күпфатирлы йорт составындагы муниципаль милек әлеге шартнамә нигезендә тапшыру объекты булып торган очракта, аны карап тоту һәм коммуналь хезмәтләр буенча чыгымнарны түләргә. Аларга түбәндәгеләр керә:

- күпфатирлы йорт белән идарә итү, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм аңа агымдагы ремонт үткәрү, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тотканда кулланыла торган салкын су, кайнар су, электр энергиясе, җылылык энергиясе белән тәэмин итү, шулай ук, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту максатыннан, агып төшә торган суларны чыгару буенча хезмәтләрне, эшләрне (алга таба – күпфатирлы йорттагы урыннарны карап тоту буенча хезмәтләр) үз эченә алган күпфатирлы йорттагы урынны карап тоткан өчен түләү;

- коммуналь хезмәтләр өчен түләү.

Ссуда алучы хезмәт күрсәтә торган һәм (яки) ресурслар белән тәэмин итә торган оешмалар белән күпфатирлы йортта торакны карап тоту буенча хезмәт күрсәтүгә, коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә килешү төзи, хезмәт күрсәтә торган һәм (яки) ресурслар белән тәэмин итә торган оешмалар тарафыннан бирелә торган счетлар нигезендә күрсәтелгән хезмәтләр өчен түли.

Ссуда алучы хезмәт күрсәтә торган һәм (яки) ресурслар белән тәэмин итә торган оешмалар тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләр өчен түләмәгән очракта һәм хезмәтләр өчен түләүгә счетлар Ссуда бирүчегә тапшырылган очракта, Ссуда алучы

---

[1] 2.1.3 пунктчасы тексты урам-юл челтәре объектлары аларны реконструкцияләү максатыннан дәүләт катнашында оешмаларга бушлай файдалануга бирелгән очракта кулланыла.

Ссуда бирүчегә күрсәтелгән счетлар буенча чыгымнарны түләүгә бәйле рәвештә тотылган чыгымнарны каплый.

Ссуда алучының әлеге пунктта күрсәтелгән чыгымнарны түләү бурычы әлеге шартнамә төзелгән вакыттан барлыкка килә;

2.2.4. әлеге шартнамәнең 2.2.2 пунктчасында күрсәтелгән файдалану максатыннан чыгып, муниципаль милекне, аннан уза торган инженерлык челтәрләрен һәм коммуникацияләрне капиталь ремонтлау, реконструкцияләү, үзгәртеп планлаштыру, яңадан җиһазлау зарурлыгы булганда, күрсәтелгән чараларны Ссуда бирүче белән язмача килештерергә һәм аларны гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә эшләнгән һәм расланган документлар нигезендә генә башкарырга;

2.2.5. Ссуда бирүче вәкилләренең, шәһәр коммуналь хезмәтләре техник персоналының инженерлык челтәрләрен һәм күзәтү астындагы җиһазларны, бина конструкциясе элементларын контрольдә тотуны һәм тикшерүне оештыру максатыннан урыннарга тоткарлыксыз керүен тәэмин итәргә;

2.2.6. хокук саклау органнары, дәүләт янгын күзәтчелеге хезмәтләре вәкилләренең гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә урыннарга керүен тәэмин итәргә[2];

2.2.7. иминиятләштерү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге шартнамә гамәлдә булган чорга муниципаль милекне иминиятләштерүне тәэмин итәргә (мондый иминиятләштерү шартнамәсе буенча файда алучы булып Ссуда бирүче тора);

2.2.8. әлеге шартнамәнең гамәлдә булу вакыты чыккан яки аны вакытыннан алда өзгән очракта, Ссуда бирүчегә муниципаль милекне кабул итү-тапшыру акты нигезендә кире кайтарырга һәм бер ай эчендә шартнамәне өзү турында килешү төзергә;

2.2.9. муниципаль милектәге торак булмаган урыннарга карата Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча федераль агентлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы «Торак фондын техник яктан эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында»гы карарына таянып эш итәргә[3].

## III. Махсус шартлар

Бушлай файдалануга мәдәни мирас объекты бирелгән очракта:

3.1. Ссуда алучы бурычлы:

3.1.1. мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән бушлай файдалануга бирелгән мәдәни мирас объекты буенча аны саклау йөкләмәсен төзергә;

3.1.2. мәдәни мирас объектларын саклау, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә мәдәни мирас объектын саклауны, аннан файдалануны контрольдә тоту максатыннан Ссуда бирүче, Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты, саклау буенча йөкләмәне рәсмиләштергән

---

[2] 2.2.3-2.2.6 пунктчалар текстына бушлай файдалануга бирелә торган муниципаль милек төренә бәйле рәвештә төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

[3] 2.2.9 пунктча күпфатирлы йортлар составында торак урын булмаган муниципаль милек бирелгән очракта кулланыла.

орган вәкилләренең муниципаль милеккә каршылыксыз керүен тәэмин итәргә;

3.1.3. мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән һәм Ссуда бирүчегә мәҗбүри хәбәр итеп башкарылган мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрдән тыш, төзелеш, тикшерү, җир белән бәйле һәм башка эшләрне гамәлгә ашырмаска;

3.1.4. мәдәни мирас объектыннан бушлай файдалану шартнамәсен дәүләт тарафыннан теркәү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3.2. Әлеге шартнамә шартлары буенча башкарылган ремонтлау-реставрацияләү эшләре мәдәни мирас объектын аерылгысыз яхшырту булып санала.

3.3. Ссуда алучы саклау буенча йөкләмәне рәсмиләштергән орган тарафыннан эшләрне башкаруга билгеләнгән вакытны бозган өчен гамәлдәге законнар нигезендә җавап бирә.

Муниципаль преференция бирелгән очракта:

3.4. Монополиягә каршы орган керткән чикләүләр: _______________________ [4].

Муниципаль милекне бушлай файдалану өчен керем китерми торган эшчәнлек белән шөгыльләнүче (хуҗалык итүче субъект булмаган), коммерциягә нигезләнмәгән оешмага биргән очракта.

3.5. Ссуда алучы елга бер тапкыр Ссуда бирүчегә салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары белән каралган, билгеләнгән тәртиптә расланган документлар күчермәсен тапшырырга тиеш. Әлеге документларның салым органы тарафыннан алынуын раслау зарур.

3.6. Ссуда алучы тарафыннан түбәндәге шартлар үтәлмәгән очракта, Ссуда бирүче әлеге шартнамәне берьяклы тәртиптә өзәргә хокуклы:

3.6.1. әлеге шартнамәнең 3.5 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмаса;

3.6.2. әгәр муниципаль милектән файдалану чорында, шул исәптән әлеге шартнамә нигезендә бирелгән муниципаль милекне кулланмыйча, керем китерә торган эшчәнлек белән шөгыльләнә башласа.

## IV. Килешүне вакытыннан алда өзү

4.1. Ссуда алучы тарафыннан түбәндәге шартлар үтәлмәгән очракта, Ссуда бирүче әлеге шартнамәне берьяклы тәртиптә өзәргә хокуклы:

4.1.1. әлеге шартнамәнең 2.2.2, 2.2.3, 2.2.3(а) пунктчалары белән каралган шартлар үтәлмәсә;

4.1.2. муниципаль милек әлеге шартнамә һәм милекнең билгеләнеше буенча файдаланылмаса;

4.1.3. муниципаль милекне төзек хәлдә тоту яки аны карап тоту буенча бурычлар үтәлмәсә;

4.1.4. муниципаль милекнең торышы сизелерлек начарайса;

4.1.5. Ссуда бирүче ризалыгыннан башка муниципаль милек өченче затка бирелсә.

4.2. Ссуда бирүче һәм Ссуда алучы Якларның язма килешүе буенча әлеге шартнамәдән теләсә кайсы вакытта баш тартырга хокуклы.

---

[4] Монополиягә каршы орган тарафыннан килештерелгәндә чикләүләр кертелсә, 3.4 пункт тутырыла.

## V. Шартнамә Якларын үзгәртү һәм аны гамәлдән чыгару

5.1. Ссуда бирүче үзгәртеп корылган яки бетерелгән очракта, шартнамә буенча аның хокуклары һәм бурычлары аның хокуклы варисы булган юридик затка күчә.

5.2. Ссуда алучы үзгәртеп оештырылган очракта, шартнамә буенча аның хокуклары һәм бурычлары аның хокуклы варисы булган юридик затка күчә.

5.3. Ссуда алучы бетерелгән очракта, әлеге шартнамә гамәлдән чыга.

## VI. Якларның җаваплылыгы

6.1. Ссуда алучы әлеге шартнамә шартларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен гамәлдәге законнар нигезендә җавап бирә.

6.2. Ссуда алучы очраклы рәвештә муниципаль милекне юкка чыгарган яки аңа зарар китергән өчен гамәлдәге законнар нигезендә җавап бирә.

6.3. Муниципаль милектән тиешенчә файдаланмау, аны сакламау, файдалану өчен яраксыз хәлгә китерү нәтиҗәсендә закон таләпләрен һәм әлеге шартнамә шартларын бозган өчен гаепле вазифаи затлар гамәлдәге законнар нигезендә дисциплинар, административ, җинаять һәм милек җаваплылыгына тартыла.

6.4. Әлеге шартнамәнең 4.1, 6.2 пунктларында күрсәтелгән хәлләр барлыкка килгәндә, Ссуда алучы Ссуда бирүчегә китергән зыянны каплый һәм муниципаль милек бәясенең 10 проценты күләмендә штраф түли.

6.5. Ссуда алучы, әлеге шартнамәнең 6.4 пунктында каралган чыгымнар үз вакытында яки тулысынча кайтарылмаган очракта, Ссуда бирүчегә кире кайтарылмаган суммадан бурычны таләп итү хокукы барлыкка килгән көнгә Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасы күләмендә һәр кичектерелгән көн өчен штраф түли.

6.6. Әлеге шартнамә белән билгеләнгән штраф санкцияләрен түләү Ссуда алучыны үз йөкләмәләрен үтәүдән яки хокук бозуларны бетерүдән азат итми.

6.7. Әлеге шартнамәдә каралган очраклардан тыш, Яклар гамәлдәге законнар нигезендә җавап бирә.

## VII. Йомгаклау нигезләмәләре

7.1. Әлеге шартнамәгә кертелә торган барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр язмача рәсмиләштерелгән һәм Якларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган очракта гына гамәлдә була.

7.2. Якларның әлеге шартнамә белән җайга салынмаган үзара мөнәсәбәтләре Татарстан Республикасында гамәлдә булган законнар белән регламентлаштырыла.

7.3. Әлеге шартнамә, гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә аны яңа вакытка төзү мөмкинлеге белән, биш елга төзелгән.

7.4. Әлеге шартнамә буенча барлыкка килә торган барлык бәхәсләр гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

7.5. Әлеге шартнамә өч нөсхәдә төзелгән, берсе Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетында саклана, икенчесе – Ссуда бирүчегә, өченчесе Ссуда алучыга тапшырыла.

## VIII. Якларның юридик адреслары һәм имзалары

Якларның адреслары һәм реквизитлары:
Ссуда бирүче:
______________________________________________________________________________
Ссуда алучы:
______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

| Ссуда бирүче: | Ссуда алучы: |
|---|---|
| __________ ____________________________ | __________ ____________________________ |
| (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме) | (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме) |
| Мөһер урыны | Мөһер урыны |

______________________